Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Ислəй авыл җирлеге Советы
карары

09.06.2023 ел №30/1

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
«Ислəй авыл җирлеге» муниципаль берəмлеге
Уставына үзгəрешлəр һəм өстəмəлəр кертү турында

«Россия Федерациясендə җирле үзидарə оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендəге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы, «Муниципаль берəмлеклəр уставларын дəүлəт теркəвенə алу турында»гы 2005 елның 21 июлендəге 97-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарə турында» 2004 елның 28 июлендəге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Ислəй авыл җирлеге» муниципаль берəмлеге Уставының 84 - 86 статьялары нигезендə, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Ислəй авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Ислəй авыл җирлеге» муниципаль берəмлеге Уставына түбəндəге үзгəрешлəрне һəм өстəмəлəрне кертергə:

1.1. 13 статьяның 12 пунктында «Җирлек сайлау комиссиясе» сүзлəрен «тавыш бирүне əзерлəүне һəм уздыруны оештыручы сайлау комиссиясе» сүзлəренə алмаштырырга;

1.2. 19 статьяда:

4 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

5 пунктны түбəндəге редакциядə бəян итəргə:

«5. Халык алдында тыңлаулар уздыру вакытын һəм урынын күрсəтеп, гавами тыңлаулар уздыру турында мəгълүмат, шулай ук гавами тыңлауларга чыгарыла торган муниципаль норматив хокукый акт проекты гавами тыңлаулар үткəрү көненə кадəр 7 календарь көннəн дə соңга калмыйча Татарстан Республикасының рəсми хокукый мəгълүмат порталында яисə җирлекнең торак пунктлары территориясендə махсус мəгълүмат стендларында, шул исəптəн Чистай муниципаль районының рəсми сайтында урнаштырылырга, шулай ук «Бердəм дəүлəт порталы һəм муниципаль хезмəтлəр (функциялəр) федераль дəүлəт мəгълүмат системасында урнаштырылырга тиеш.»;

6 пунктны түбəндəге редакциядə бəян итəргə:

«6. Гавами тыңлаулар һəм муниципаль норматив хокукый акт проекты басылып чыккан (халыкка җиткерелгəн) көннəн башлап, җирлек халкы халык тыңлауларына чыгарылган муниципаль норматив хокукый акт проекты яисə мəсьəлəсе буенча, шул исəптəн «Дəүлəт һəм муниципаль хезмəтлəр (функциялəр) бердəм порталы» федераль дəүлəт мəгълүмат системасы ярдəмендə, тəкъдимнəр һəм искəрмəлəр җибəрергə хокуклы.

Җирлек башлыгы кергән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне гомумиләштерүне оештыра һәм аларны гавами тыңлауларда катнашучыларга җиткерә.»;

9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында яисә Җирлек торак пунктлары территориясендә махсус мәгълүмат стендларында урнаштырылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш, шул исәптән Чистай муниципаль районының рәсми сайтында һәм “Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы” федераль дәүләт мәгълүмат системасында гавами тыңлаулар уздырганнан соң 5 көннән дә соңга калмыйча урнаштырылырга тиеш.»;

1.3. 28 статьяның 7 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) » сүзләренә алмаштырырга;

1.4. 38 статьяга түбәндәге эчтәлекле 2.1 пункт өстәргә:

«2.1. Җирлек Советы депутаты җитди сәбәпләрсез алты ай рәттән җирлек Советының оештырылган бар утырышларында булмаган очракта, җирлек Советы карары белән җирлек Советы депутатының вәкаләтләре вакытыннан алда туктатыла.»;

1.5. 40 статьяның 1 пунктының икенче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) » сүзләренә алмаштырырга;

1.6. 44 статьяның 4 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы  (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга;

1.7. VII бүлек үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен җибәрергә.

3. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Исләй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына кертелгән үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне дәүләт теркәвеннән соң билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Исләй авыл җирлеге башлыгы В.П.Чернышев